**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**28 НОМЕРЛЫ КАРАРЫНА**

**КАРАРЫ**

2016 ел, 16 апрель №28

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмә хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 25 декабрендәге 73-ФЗ номерлы Указы, «Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын башкаруында һәм шәхси кызыксынулары турында хәбәр итү тәртибе хакында» Россия Федерациясе Президентының 2016 елның 18 мартындагы 265-ПУ номерлы Указы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте :

1. Түбәндәгеләрне расларга:

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтын чыгара яисә чыгарырга мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмә (Кушымта)

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас муниципаль районы башлыгы урынбасары М.Г. Нуриевка йөкләргә.

**Р.Н. Заһидуллин**

**Апас муниципаль районы башлыгы - Апас муниципаль районы Советы Рәисе**

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Советының 2016 елның 16 апрелендәге
28 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Апас муниципаль районындагы муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

Хәбәр вазифаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр рәвешендә язма рәвештә рәсмиләштерелә (алга таба - хәбәрнамә).

3. Муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча төзелгән хәбәрнамәне җибәрә.

4. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе 2 нче кушымтада каралганча форма буенча төзелгән Апас муниципаль районы башлыгына хәбәр җибәрә.

5. Апас муниципаль районы составына керүче авыл (шәһәр) җирлеге башлыгы Апас муниципаль районы Советы рәисенә 3 нче кушымтада каралганча форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрә.

6. Апас муниципаль районы башлыгы, Апас муниципаль районы Советы рәисе, Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына килгән мөрәҗәгатьләр карау өчен муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы мәнфәгатьләре конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба - Комиссия) тапшырыла.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында Комиссия хәбәрнамәләр җибәргән затлардан аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга һәм билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар җибәрергә хокуклы.

7. Хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән нәтиҗә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар Комиссия утырышына тапшырыла, ул Комиссиягә хәбәрнамәләр кергән көннән алып җиде эш көне эчендә уздырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гарызнамәләр, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар җибәрелгән очракта, Апас муниципаль районы башлыгына, Апас муниципаль районы Советы рәисенә яисә Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә хәбәр килгән көннән алып 45 көн эчендә Комиссиягә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артык түгел.

8.Комиссия, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, Апас муниципаль районы Советының 2015 елның 16 гыйнварындагы 234 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу һәм алар буенча карарлар кабул итә һәм кабул иткән карарларны Апас муниципаль районы башлыгына, Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрә.

9. Апас муниципаль районы башлыгы, Апас муниципаль районы Советы рәисе, Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, Комиссия караганнан соң түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликты булмавын танырга;

б) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан шәхси кызыксынучанлык мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин дип танырга;

в) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чаралары үтәлмәгәнлеген танырга.

10. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә Апас муниципаль районы башлыгы, Апас муниципаль районы Советы рәисе яисә Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чараларын күрә яисә аларны булдырмау буенча чаралар күрүне тәэмин итә йә хәбәрнамә җибәргән затка шундый чаралар күрергә киңәш итә.

11. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Апас муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы, Апас муниципаль районы Советы рәисе, Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылык чараларын кулланалар.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районында
муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар
тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә
шәхси кызыксынучанлык
барлыкка килү турында хәбәр итү
тәртибе турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

____________________________
(танышу турында тамга)

_______________________________________
(Совет рәисенә, Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә (кирәклесен сайларга)

_____________________________________
(Ф.И.О., вазыйфа)

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган
шәхси кызыксыну барлыкка килү турында
ХӘБӘРНАМӘ

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: ____________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлыгы йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар: __________________________________________

________________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: _________________________________________________________

________________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы____________________________муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләнәм (искәртергә кирәк).

"____"________________ 20___

(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районында
муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар
тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә
шәхси кызыксынучанлык
барлыкка килү турында хәбәр итү
тәртибе турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта

__________________________
(танышу турында тамга)

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгына
___________________________________
(Ф.И.О., вазыйфа)

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган
шәхси кызыксыну барлыкка килү турында
ХӘБӘРНАМӘ

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: ________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлыгы йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар: ______________________________________
____________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ____________________________________________________
____________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы__________________________муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләнәм (искәртергә кирәк).

"____"________________ 20______________

(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районында
муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар
тарафыннан вазыйфаи бурычларны үтәгәндә
шәхси кызыксынучанлык
барлыкка килү турында хәбәр итү
тәртибе турындагы нигезләмәгә
3 нче кушымта

_______________________________
(танышу турында тамга)

Апас муниципаль районы Советы рәисенә

__________________________________________
(Ф.И.О., вазыйфа)

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган
шәхси кызыксыну барлыкка килү турында
ХӘБӘРНАМӘ

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: ___________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлыгы йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар: _____________________________________________

__________________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы_______________________________муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләнәм (искәртергә кирәк).

"____"_______________ 20___

(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (имзаның аңлатмасы)